**Ия Белән Хәбәр кыйссасы**

**(Эссе)**

Мин, Әхмәтҗанова Әлфия Фарух кызы, Арча районы Күпербаш авылында укытучы гаиләсендә туганмын.

Нәсел шәҗәрәбездә җиде буын укытучылар булган нәсел без.

Гаиләбез шук теллелеге, намуслы, кешелекле булуы белән авылдашларым арасында хөрмәт казанган гаилә.

1980нче елда әти- әнием мине мәктәпкә озаттылар. Әнием миңа:

- Кызым, ия белән хәбәрне тапканчы тырышып укы. Алар синең киләчәгеңә ачкыч булыр , - дип парта арасына кертеп утыртты.

Дәрескә беренче кыңгырау чылтырады.

-Кайда икән инде бу ачкычлар?- диеп, як – ягыма каранам, парта астына да төшеп мендем, сумкамнан да эзләп карадым. Ләкин ачкычлар беркайда да юк иде.

-Үскәнем, нәрсә таба алмыйсың?- дигән ягымлы тавыш ишетелде.

Бу минем беренче укытучым Сөмәя апа иде.

-Әнием миңа ия белән хәбәр дигән ачкыч табып алып кайтырга кушты. Ә алар беркайда да юк ,- дип, мин елап җибәрдем.

-Табабыз без аларны. Тик аларны сумкадан, парта астыннан түгел, китаптан, дәфтәрдән эзләргә кирәк, - дип назлап, укытучым мине мәктәп тормышына алып кереп китте. Мин шул вакыт үзем дә укытучы булу теләге уянганын сиздем. 8ел сизелми үтеп китте.

Укытучы булу теләген тормышка ашыру өчен Арча педагогика училищесына укырга кердем. Мөнирә Әхмәтовна ия белән хәбәрне әй эзләтте, әй эзләтте соң! Бу эш шулкадәр мавыктырды, дүрт ел үтеп киткәне сизелмәгән дә.

Инде үзем укытучы булдым. Тик ия белән хәбәр һаман да миңа тынычлык бирми бит! Гел аларны табасы гына килеп тора!

Кызыксынуым мине Казан дәүләт педагогика университетына алып килде. Менә дигән татар телчеләре укытты безне анда: Асылгәрәева Роза Әминовна, Харисова Чулпан Мөхәрләмовна, Галимуллин Фоат Галимулович... Алар бездән менә дигән татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләп мәктәпләргә озаттылар.

Мин - татар теле һәм әдәбияты укытучысы !

Туган телебезгә, халкыма, мәдәниятыбызга мәхәббәт тәрбияләүнең бер өлеше өчен хәзер мин җаваплы. Укучыларым ия белән хәбәрне китап һәм дәфтәрләрдән генә эзләргә риза түгел, аларга заман таләпләренә туры килгән методлар кирәк булып чыкты. Методик темамны укучыларның ихтыяҗларына туры килерлек итеп эшләргә тырыштым. ,, Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыруда инновацион технологияләр кулланып, татар теле һәм әдәбияты дәресләренә укучыларда кызыксыну уяту” дигән тема өстендә эшлим.

Мәктәбебез шартлары миңа дәресләрдә төрле видео техниканы уңышлы кулланырга мөмкинлек бирә. Кабинетым интернет челтәренә тоташтырылган компьютер, принтер, сканер, интерактив такта, проектор белән җиһазландырылган. Ә бу мөмкинлекләр мине даими рәвештә укытуның яңадан-яңа алымнарын эзләргә этәрә. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә компьютерның мультимедия мөмкинлекләреннән киң файдаланам. Дәресләрдә төрле видео, презентацияләр кулланам. Сөйләм теле үстерү дәресләрендә презентацион Power Point программасында укыган әсәргә иллюстрацияләр ясыйм, аларны принтер аша чыгарып укучыларга да таратам.

Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли.

Үз белемен күтәрү өстендә эшләмәгән укытучы укытучы түгел. Мин дә заманнан арта калмас өчен төрле белем күтәрү курсларына йөрим. Алган белемнәрне дәресләрдә генә куллану белән чикләнергә ярамый. Мин укучыларымнан да шуны таләп итәм.

Ия белән хәбәрне эзләгәндә төрле ачышлар ясыйбыз. Аларны укучылар белән төрле конференцияләрдә катнашып уртаклашабыз . Ныклы әзерлек белән катнашуыбыз үзенең нәтиҗәләрен бирә, югары урыннарга ирешәбез.

Район һәм шәһәр конкурслары да минем укучыларымнан башка узмый. ,, Татар егете", ,, Татар кызы", ,, Татар җыры" һәм башка конкурсларда актив катнашабыз.

Мине мәктәп тормышы мине шулкадәр мавыктырган , 23 ел күз ачып йомганчы узып та киткән. Башкалар белән уртаклашырлык эш нәтиҗәләрем дә байтак җыелган. Аларны интернет челтәренең төрле тармакларына урнаштырдым. Үземнең шәхси сайтым да бар. "Белем җәүһәрләре" бөтендөнья интернет-проектлар бәйгесендә катнашып, 3нче дәрәҗә дипломга ирештем.

Колагымда әнием сүзләре яңгырый: ,, Ия белән хәбәрне табарга тырыш. Алар – тормыш ачкычлары." Әйе, әнием сүзләрендә бик тирән мәгънә ята икән. Чыннан да, алар гомеремнең һәр этабына яңа ачкыч икән бит!

Беренчедән- алар мине туган туган телемне , халкымны, гореф-гадәтләремне сакларга өйрәтте.

Икенчедән –үз балаларымны, укучыларымны туган телдә тәрбиялим.

Өченчедән –яраткан һөнәремне табарга ярдәм итте.

Эзлим, әледә эзлим мин ия белән хәбәрне. Тик үзем генә түгел: гаиләм, укучыларым, хезмәттәшләрем белән бергә эзлим.

Туган телем, халкым яшәгәндә эзләрбез, югалтмабыз без сезне, Ия белән Хәбәр!